| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2021 с.Старое Дрожжаное №81

«Торак фонды өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» 2019 елның 07 маендагы 200 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 07 маендагы 200 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (1 нче кушымта):

2.6 пунктның икенче баганасында:

1 пунктчаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1) Яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;»;

түбәндәге эчтәлекле 5-9 пунктчалар белән тулыландырырга:

«5) 14 яшькә җитмәгән мөрәҗәгать итүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

6) Мөрәҗәгать итүче һәм/яки аның гаилә әгъзалары өчен никах теркәү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

7) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

8) Никахны өзү турында таныклык - гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

9) Опека билгеләү турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фондына.».

2.4.1

«йорт китабыннан өземтәләрне» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5-9 пунктчалар белән тулыландырырга:

«5) бала туу турында таныклык;

6) никахлашу турында таныклык;

7) ата булуны билгеләү турында таныклык;

8) никахны өзү турында таныклык;

9) опека билгеләү турында белешмәләр.».

1.2. гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (2 нче кушымта ):

2.5 пунктындагы икенче баганада 6 пунктчаны төшереп калдырырга;

2.6 пунктның икенче баганасында: 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;»;

түбәндәге эчтәлекле 3-7 пунктчалар белән тулыландырырга:

«3) 14 яшькә җитмәгән гариза бирүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

4) Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никах төзү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

5) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

6) Никахны өзү турында таныклык - гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

7) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия фондына.».

3.4.1 пунктта:

«Йорт китабыннан өземтәләр (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта)» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3-7 пунктчалар белән тулыландырырга:

«3) бала туу турында таныклык;

4) никахлашу турында таныклык;

5) ата булуны билгеләү турында таныклык;

6) никахны өзү турында таныклык;

7) опека билгеләү турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма кометет
Җитәкчесе Д.А.Сатдинов